ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

04.09.2019

№1344

Муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында» 2018 нче елның 29 нчы декабрендәге 1270 нче номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, 2018 нче елның 13 нче декабрендәге «2019, 2020, 2021 нче елларга Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең план чоры бюджеты турында»гы 311 нче номерлы АМР Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге арасында 2019 нчы елда педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында төзелгән килешүне үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына Алабуга муниципаль районының мәгариф идарәсенә педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүләрне гамәлгә ашыру өчен ведомство карамагындагы мәгариф учреждениеләренә максатчан субсидия бирүгә ассигнованиеләр бирергә тәкъдим итәргә.
2. Алабуга муниципаль районының мәгариф идарәсенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге арасында 2019 нчы елда педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү

турындагы килешү нигезендә бүлеп бирелгән акчалардан файдалануны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамыгымда калдырам.

Җитәкче в.б. Л.Ф. Нургаянов